**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЫЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2018 ел, 7 март № 88

**Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең 18 бүлегенә үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Кызылтау авыл җирлеге Советының 2016 ел, 12 февраль 16 номерлы "Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында" карарының 1 номерлы Кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

18 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 18.5 пунктын өстәргә:

«18.5. Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге взысканияне куллану турындагы мәгълүматлар муниципаль хезмәткәр хезмәт узган җирле үзидарә органы тарафыннан Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы Официаль порталына һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы официаль сайтының җирлекләр бүлегенә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемндә калдырам.

**Кызылтау авыл**
**җирлеге башлыгы** **Ш.Р.Гаффаров**